# ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯЛӘР

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯЛӘР

*Лүк бәян иткән «Яхшы хәбәр»дән*



ИЗГЕ КИТАПНЫ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ИНСТИТУТЫ
2017

# Гыйбрәтле хикәяләр

## *Лүк бәян иткән «Яхшы хәбәр»дән*

*С.М. Хакуз рәсемнәре*

Әлеге китапның текстын һәм аудио язмасын Изге Китапны тәрҗемә итү институтының сайтыннан (*http://ibt.org.ru/ru/audio?id=TTR*) табарга мөмкин.

ISBN 978-5-93943-242-9

© Институт перевода Библии, 2017

## *Кереш сүз*

*Кадерле укучылар! Әлеге китапта акыл һәм зирәклекнең нинди зур хәзинә булуы турында сүз бара. Китапка кергән дүрт кыска хикәя инде күп телләргә тәрҗемә ителгән. Гайсә Мәсих сөйләгән бу хикәяләрне Аның тарафдары булган табиб Лүк I нче гасырда язып калдырган. (Шушы хикәяләр урын алган Инҗил китабы татар телендә – 2001 нче, ә Тәүрат, Зәбур һәм Инҗилне берләштергән «Изге Язма» җыентыгы 2015 нче елда басылып чыкты.) Моннан ике мең еллар элек Фәләстин илендә яшәгән халыкка шушы хикәяләр зур тәэсир ясаган кебек, бүгенге көндә дә алар безне битараф калдырмыйлар – тормышыбыздагы гаять мөһим мәсьәләләр турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Акча, дан-дәрәҗә артыннан куучыларны, дини гореф-гадәтләрне төп-төгәл үтәргә өндәүчеләрне мактаган*

*китаплардан аермалы буларак, әлеге хикәяләрдә авыру-зәгыйфь яисә сөйкемсез кешеләрнең дә Аллаһы өчен кадерле, кыйммәтле булуы турында сөйләнә. Кулыгызга алган шушы китаптагы хикәяләр рәсемнәр белән җанландырылган, һәм алар сезгә укып барган вакыйгаларны күз алдына китерергә һәм китапның эчтәлеген тагын да тирәнрәк аңларга булышыр. Әлеге гаҗәеп хикәяләр татар укучысында да чын кызыксыну уятыр дип өметләнәбез.*

*Китапны басмага әзерләүдә катнашкан тәрҗемәчегә, мөхәррирргә һәм рәссамга Изге китапны тәрҗемә итү институты үзенең рәхмәтен белдерә.*

*Изге Китапны тәрҗемә итү институты*

# Бер кешенең юлдан язган улы турында гыйбрәтле хикәя

*(Лук 15:11-32)*

*Фәләстин илендә яшәүче дин әһелләре Гайсәнең дин юлында булмаган, димәк ки гөнаһ ияләре дип саналган кешеләр белән аралашуын өнәмәгәннәр. Гайсә, дин әһел-ләренең гаепләүләренә җавап итеп, бала җанлы ата һәм аның ике улы турында гыйбрәтле бер хикәя сөйли. Әти булган кеше биредә — мәрхәмәтле Аллаһыны, кече улы — юлдан язган гөнаһлы бәндә-ләрне, ә өлкән улы гөнаһлыларны хөкем итүче дин тотучыларны гәүдәләндерә.*



Бер кешенең ике улы булган. Шуларның кечерәк дигәне атасына: «Әти, милекнең миңа тиешле өлешен бүлеп бир», – дигән. Атасы үзенең милкен улларына бүлеп биргән.



Берничә көн үткәч, кече улы, үз өлешен сатып, булган акчаны үзе белән алып, ерак илгә чыгып киткән һәм анда, азгынлыкка бирелеп, байлыгын туздырып бетергән.





Ул шулай бөтен байлыгын туздырып бетергәннән соң, бу илдә бик каты ачлык башланып, егет мохтаҗлыкта калган. Шуннан ул җирле бер кешегә эшкә ялланган, һәм теге аны үзенең басуына дуңгыз көтәргә җибәргән. Егет шулкадәр ачка интеккән, хәтта дуңгызлар ашый торган азыкка да шат буласы

икән, ләкин аңа беркем бернәрсә бирмәгән. Шуннан ул, акылына килеп: «Атамның күпме ялчысы туйганчы ризык ашый, ә мин монда ачка тилмерәм! Хәзер үк атам янына кайтыйм да:







„Әти, мин Күктәге Аллаһы каршында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, инде мин синең улың дип аталырга да лаек түгелмен; ялчыларыңның берсе булырга рөхсәт ит миңа“, – дип әйтим», – дигән дә атасы янына кайтып киткән. Атасы аны, ерактан ук күреп алып, бик кызганган, каршына йөгереп барып кочаклап үпкән.



Улы исә аңа: «Әти, мин Күктәге Аллаһы каршында һәм синең алдыңда гөнаһ кылдым, инде синең улың дип аталырга да лаек түгелмен», – дигән. Әмма атасы үзенең хезмәтчеләренә: «Тиз генә аңа затлы киемнәр алып килегез, аягына – сандал, бармагына йөзек кидерегез. Шуннан соң симертелгән

берәр бозауны чалыгыз. Сыйланыйк, күңел ачыйк! Минем бу улым үлгән иде, хәзер терелде, югалган иде – инде табылды», – дигән, һәм алар бәйрәм итә башлаганнар.



Аның өлкән улы исә бу вакытта кырда бул-
ган. Өенә кайтып җитәрәк, ул җыр-бию та-
вышлары ишеткән. Хезмәтчеләрнең берсен
чакырып: «Бу ни хәл?» – дип сораган. Хезмәт-
че аңа: «Синең энең кайтты, аның сау-сәламәт





әйләнеп кайтуына куанып, атаң симертелгән бозау чалдырды», — дигән. Өлкән улының моңа ачуы килгән, һәм ул өйгә керергә теләмәгән. Атасы, чыгып, аның өйгә керүен үтенгән. Әмма атасына җавап итеп, ул: «Менә

мин сиңа күпме еллар кол сыман хезмәт итәм, кушканыңны һич үтәми калганым юк, алай да дусларым белән күңел ачарга синең миңа беркайчан кәҗә бәтие дә биргәнең булмады. Ә инде милкеңне фахишәләр белән туздырып бетергән бу улың кайткач, аның өчен симертелгән бозау чалдыргансың!» – дигән. Атасы исә аңа: «Улым, син һәрвакыт минем янда, минем бөтен нәрсәм синеке, – дигән. – Шатланырга, күңел ачарга безнең сәбәп бар, чөнки синең энең үлгән иде, хәзер терелде, югалган иде – инде табылды».



# Шәфкатьле самарияле турында гыйбрәтле хикәя

*(Лук 10:30-35)*

*Фәләстин илендә төрле халыклар яшәгән. Шуларның икесе – яһүдләр белән самареялеләр – төрле диндәге, төрле гореф-гадәтләргә буйсынучы кавемнәр булып, бер-берсе белән аралашмыйча, дошмани мөнәсәбәтләрдә яшәгәннәр. Самареялеләр кебек үк яһүдләр дә үзләренең якыннарына яхшы мөнәсәбәттә һәм игелекле булулары белән горурланганнар. Әмма Гайсәнең түбәндәге хикәясендә яраткан кешеңә генә түгел, ә бәлки янәшәңдәге кешегә дә яхшылык кылуның чын яхшылык булуы сөйләнә. Биредә бәлагә юлыккан яһүд кешесенә һич көтмәгәндә бер самареяле адәмнең ярдәм кулы сузуы бәян ителә.*



Бер кеше, Иерусалимнән Әрихә каласына барганда, юлбасарлар кулына эләккән. Алар әлеге юлчыны талаганнар һәм, кыйнап, үлем хәлендә калдырып киткәннәр.



Бер руханига шул юлдан барырга туры килгән, әмма ул, шунда яткан кешене күргәч, юлның икенче ягына чыгып, ары киткән. Шулай ук левиләрдән, ягъни руханилар

булышчысыннан да берәү узып барышлый
аны күргән дә юлның икенче ягына чыгып



китеп барган. Бер самареяле исә, үтеп барганда бу кешегә тап булып, аны бик кызганган: янына килеп, яраларын шәраб





белән юган, зәйтүн мае сөртеп бәйләгән, аннары, үзенең ишәгенә атландырып,



кунак йортына алып килгән һәм анда да әлеге юлчыны ярдәменнән ташламаган.





Ә икенче көнне, юлга чыгарга җыенганда, кунак йорты хуҗасына ике көмеш тәңкә биреп: «Аның хакында кайгыртчы, – дигән. – Әгәр күбрәк акча тотсаң, кире кайтканда түләрмен».

# Мәҗлескә чакыру турында гыйбрәтле хикәя

*(Лук 14:16-24)*

*Мәҗлескә чакырылу — зур дәрәҗәдер. Әмма мәҗлескә баруга еш кына төрле җитди сәбәпләр яисә тормыш мәшәкатьләре комачауларга мөмкин. Бервакыт шулай Гайсә ашка килгәч, кунакларның берсе: «Аллаһы Патшалыгындагы мәҗлестә сыйланырга насыйп булган кеше фатиха ияседер», — дип әйтә. Бу сүзләргә җавап итеп, Гайсә гыйбрәтле бер хикәя сөйли. Әлеге хикәядә Аллаһы Патшалыгындагы мәҗлескә чакырылу ашка чакырылу белән чагыштырыла. Мәҗлескә күпләр чакырылыр, әмма килгән кунакларның кайберләре бөтенләй көтелмәгән кунак булырга да мөмкин.*



Бер кеше, зур аш мәҗлесе үткәрергә җыенып, күп кунаклар чакырган һәм, табынга утырыр вакыт җиткәч, чакырылган кешеләргә: «Килегез, инде бар нәрсә әзер», — дип әйтергә үзенең хезмәтчесен җибәргән. Барысы



да сүз берләшкән кебек гафу үтенә башлаган. Беренчесе: «Җир сатып алган идем, шуны барып карарга кирәк, зинһар, гафу ит», –

дигән. Икенчесе: «Биш пар үгез сатып алган идем, хәзер шуларны эштә сынап карамакчы булам, зинһар, гафу ит», – дигән.





Өченчесе: «Мин әлерәк кенә өйләндем, шуңа күрә килә алмыйм», – дигән. Хезмәтче, кайтып, бу хакта хуҗасына хәбәр иткән. Хуҗаның ачуы чыгып, хезмәтчесенә ул: «Бар, тиз



генә шәһәр урамнарыннан һәм тыкрыклар-
дан фәкыйрь, гарип, сукыр һәм аксакларны
җыеп алып кил», – дигән. Берникадәр вакыт

үткәч, хезмәтче аңа: «Хуҗам, әмереӊ үтәлде, әле тагын да буш урыннар бар», – дигән. Хуҗа исә хезмәтчесенә: «Бар, шәһәр читенә





чыгып, юлларны, койма буйларын карап уз һәм кешеләрне монда килергә кыста, өем тулы кунак булсын, – дигән. – Сезгә әйтәм:

элек чакырылганнарның берсе дә сый нигъ-
мәтемне татымас».



# Фарисей һәм салым җыючы турында гыйбрәтле хикәя

*(Лук 18:10-14)*

*Фарисейләр Аллаһының изге китапларында язылган Муса кануннарының һәммәсен төгәл үтәргә, көнгә берничә тапкыр дога кылырга, сәдака таратырга, кабул ителгән гореф-гадәтләрнең барысын тайпылышсыз башкарырга тырышканнар һәм бүтәннәрне дә шуңа өндәгәннәр. Аларның күпчелеге үзләрен Аллаһы каршында бик тәкъва дип санаганнар. Ә менә салым җыючылар, башкара торган хезмәтләре аркасында, хөрмәт һәм дан-дәрәҗәдән мәхрүм булганнар, тәкъвалардан саналмаганнар. Гайсә Үзенең бер вәгазендә Аллаһы йортына дога кылырга дип килгән фарисей һәм салым җыючы турында гыйбрәтле хикәя сөйли.*



Ике кеше, дога кылу өчен, Аллаһы йортына кергән: аларның берсе фарисей, ә икенчесе салым җыючы икән. Фарисей, алгарак чыгып, болай дип дога кылган: «Йа Аллаһы! Башкалар кебек талаучы да, алдакчы да, зина кылучы да яки менә бу салым җыючы кебек тә



түгелмен. Шуның өчен Сиңа шөкер әйтәм. Атнага ике тапкыр ураза тотам, табышымның уннан бер өлешен гошер сәдакасы итеп бирәм». Читтәрәк басып торган һәм күзләрен күтәреп күккә карарга да батырчылык итмәгән салым җыючы исә күкрәгенә суга-суга: «Йа Аллаһы! Мин гөнаһлыны мәрхәмәтеңнән аерма!» – ди

икән. Сезгә әйтәм: фарисей түгел, нәкъ менә салым җыючы Аллаһы тарафыннан акланып кайтып киткән. Чөнки үзен күтәрүче һәркем түбәнсетелер, ә үзен түбәнсетүче – күтәрелер.



